**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 11 ноябрендәге 3886 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы «Вахитов районының Бауман урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Шәһәр төзелеше вәзгыятенең үзгәрүе белән бәйле рәвештә, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте мөрәҗәгате нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы «Вахитов районының Бауман урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 20 гыйнварындагы 48 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. исемен түбәндәге редакциядә бирергә: «Вахитов районы Бауман урамындагы җир кишәрлегенә ачык сервитут билгеләү турында»;

1.2. 1 һәм 4 пунктларда «1, 2 һәм 3 номерлы кушымталар нигезендә» сүзләрен «1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1.1 пунктчасында:

1.3.1. «132 кв.м» сүзләрен «70 кв.м» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.2. «хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:010215:20, 16:50:010215:27» сүзләрен «хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры 16:50:010215:788» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 5 пунктта «3 номерлы кушымтадан кала» сүзләрен «2 номерлы кушымтадан кала» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 1, 2, 3 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.6. әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарын шул ук тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 гыйнварындагы 153 номерлы карарының 1 һәм 2 номерлы кушымталары дип санарга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.


3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 11 ноябрендәге
3886 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




| | |
|---|---|
| Масштаб 1:100<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (гамәлдәге) |
| | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| 16:50:010215 | Кадастр кварталы |
| 16:50:010215:788 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |